ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

“Россия Федерациясе Гаилә кодексының 113 статьясына һәм “Үтәтү эшен алып бару турында” Федераль законның 102 статьясына үзгәрешләр кертү хакында” федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында

Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. “Россия Федерациясе Гаилә кодексының 113 статьясына һәм “Үтәтү эшен алып бару турында” Федераль законның 102 статьясына үзгәрешләр кертү хакында” федераль закон проектын закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертергә.
2. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына, шулай ук Татарстан Республикасыннан сайланган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының әлеге закон чыгару инициативасын хуплауны сорап мөрәҗәгать итәргә.
3. Әлеге закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында караганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми вәкиле итеп Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Гыйльметдинов Илдар Ирек улын билгеләп куярга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2019 елның 5 июне
№ 2905-V ДС